

# *Туган ягым буйлап күңелле сәяхәт*



Түбән Кама
2012

Түбән Кама Муниципаль районы башкарма комитетының "Мәктәпкәчә мәгариф идарәсе" муниципаль бюджет учреждениесе каршында оештырылган координацион советы утырышында расланды.

Авторлар: Гафурова Н.В.– Түбән Кама шәһәре, 25нче балалар бакчасының беренче категорияле тәрбиячесе.
Хузягалиева Г.М. - Түбән Кама шәһәре, 25нче балалар бакчасыныц югары категорияле өлкән тәрбиячесе, РСФСР халык мәгарифе отличнигы.

Рецензент: Гатауллина Резеда Фарвазовна – педагогия фәннәре кандидаты, Казан шәһәре Икътисад, идарә һәм хокук институтыныц Түбән Кама филиалы, гомуми психология кафедрасы, психолог.

# Туган ягым буйлап күңелле сәяхәт

Методик кулланма

Балалар бакчаларында эшләүче педагогларга, ата-аналарга, педагогия училищесы студентларына, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга экологик тәрбия бирү буенча методик кулланма.

**Саклануга мохтаж дару үләннәре. Аларны исеңдә калдыр!**


**Мәтрүшкә**


**Сары мәтрүшкә**


**Елан тамыры**


**Кәнәфер**

**Бу чәчәкләр Татарстанда үсә һәм Кызыл китапка кертелгән.**


**Умырзая (подснежник)**


**Кыңгырау чәчәк (колокольчик)**

Хөрмәтле ата-аналар, тәрбиячеләр, балалар!

Сезнең игътибарыгызга мәктәпкәчә яшьтәге балаларны туган ягыбызның табигате белән таныштыру, аның үсемлек һәм җәнлекләр дөньясын өйрәтү эшендә ярдәмлек булып торган китап тәкъдим итәбез.
Эчтәлеге балаларда танып белү активлыгын үстерүгә, табигатькә сак караш һәм дөрес мөнәсәбәт формалаштыруга, табигатьне бербөтен итеп кабул итүгә, туган як табигате турында күбрәк белергә теләк уятуга юнәлтелгән.

Китапта туган ягыбызның матурлыгын чагылдырган елга һәм күл буйлары, урман һәм болыннарның фотосурәтләре, табигать һәм табигатьтә яшәүче тере җаннар турында кызыклы шигырьләр, табышмаклар, рәсемнәр, аңлатмалар, күп кенә кызыклы биремнәр, ял минутлары һ.б. бар. Китап 5-7 яшьтәге балаларга тәкъдим ителә.

Без сезне туган ягыбызның табигате буйлап кызыклы сәяхәткә чакырабыз. Бу сәяхәт гади түгел. Аның өчен беркая да барырга кирәкми. Сәяхәт вакытында сез күп кенә табигать серләрен ачарсыз. Хәерле юл сезгә!

Гатауллина Р.Ф.

Әйдәгез урманга һәм кырга
Табигать китабын укырга.
Бу китап гаять зур, гаять бай.
Анда бар:
Җир,
Су,
Күк,
Кояш,
Ай.

(Җ. Тәрҗеманов «Табигать китабы»)



Сәлам сиңа, нәни дускай!
Мин булам үзем тычкан.
Бик күпне беләсем килә,
Шулай ук мин тырыш та.
Әйдә инде таныш булыйк
Чыелдык – минем исем.
Ә хәзер менә синекен
Минем килә беләсем.

Әгәр, дустым,  яза белсәң
Исемеңне язып куй.

Әнә уңда минем сурәт.
Ә синеке кая соң?

Туган ягым табигатен
Мин, дустым, бик яратам.
Хәзер сине үзем белән
Сәяхәткә чакырам.
Аның өчен кирәк түгел
Әллә - кая  барырга,
Төрле кирәк-ярак сорап
Зурларны аптыратырга.
Җайлап урындыкка утыр,
Ал төсле карандашлар,
Абый  я апаңны чакыр
Һәм сәяхәтне башла.

Барырбыз без синең белән
Бу китап битләреннән.
Тизрәк китик инде әйдә
Күңелле сәяхәткә





Сәяхәткә дуслар белән
Баруы бик күңелле.
Хәзер сине алар белән
Таныштырып үтәрмен.



Зирәк булсаң табышмакка
Син җавап табып кара
Һәм табышмакның җавабын
Ясап куй син уртага.

**Табышмак:** Лампа түгел – яктырта,
Мич түгел – җылыта
Ул булса, көн була.
Ул булмаса, төн була.



Ясадыңмы? Бусы булды
Минем беренче дустым.
Калганнары белән алда
Син әле танышырсың.

**Бирем.** Кояш тирәсендәге рәсемнәргә игътибар ит. Анда нәрсәләр ясалган? Уйлап кара, кояш җылысы һәм яктысы кемнәргә кирәк?
Аңлатып бир.
Ул рәсемнәрне кояш белән тоташтыр, төсле карандашлар белән буя

Менә минем дустым – Тамчы.
Сиңа ул таныш яхшы.
Үсемлекләр, җәнлекләр дә
Яраталар Тамчыны.
Тик торырга яратмый ул,
Һәрвакыт хәрәкәттә:
Я һавада, я ул җирдә -
Туктаусыз сәяхәттә.

**Бирем.** Тамчы, су кемгә кирәк соң?
Син дустым яхшы уйла.
Һәм буш түгәрәкләргә
Аның сурәтен яса.

**Схема: су кемнәргә, нәрсәләргә кирәк?**



Яңгыр булып тамчы тама
Урман, басу, тауларга.
Гөрләвекләр булып ага
Һәм кушыла елгага.
Назлангач кояш нурында,
Оча тамчы һавага
Һәм җир йөзенә тагын
Ул яңгыр булып кайта.





**Бирем.**

1. Рәсемгә кара, тамчының сәяхәте турында сөйлә.
2. Рәсемне буя, кояш нурларын, болыттан ява торган яңгырны яса.
3. Уклар белән табигатьтәге су әйләнешен күрсәт.
4. Табышмакка җавап бир:

Йөзәм, ләкин суда түгел,
Йөзәм сезнең өстә мин.
Шат чагында ап-ак булам,

Кайчак кара төстә мин  (болыт)




Табышмакның җавабын рәсемдә күрсәт.
Мин табышмак яратамын,
Бик яратам, чынлап та.
Табышмакларны син тагын
Очратырсың китапта.
Ә әлегә монысына
Син җавап табып кара.

**Табышмак.**
Мине алып йөрсәгез,
Карурманга керсәгез,
Диңгезләрдә йөзсәгез,
Онытмагыз сез шуны –
Белмәссез  адашуны.

**Бирем.** Табышмакның җавабы  беренче буш түгәрәктә ясалган. Уйла,  сәяхәтчегә сәяхәттә тагын нәрсәләр бик кирәк?
Калган буш түгәрәкләргә рәсемен яса һәм төсле карандашлар белән буя.






Колач җәеп каршы ала,
Сулышларны киңәйтә,
Кайчак ул караңгы, шомлы…
Исемен аның әйт әйдә!
(урман)

Чү? Нәрсә бу? Карап торам,
Бернәрсә дә аңламыйм.
Урманыма нәрсә булган?
Мин аны һич танымыйм.



**Бирем.** 1. Рәсемгә кара. Синең мондый урманда йөрисең киләме? Ни өчен?

2. Урманны тәртипкә китер: чүпкә, учакка ак кәгазь ябыштыр. Җиләк-җимеш куагы, җир җиләге, энҗе чәчәге һәм үзеңә ошаган җәнлек рәсемен яса, төсле карандашлар белән буя.

3. Табигатьтә йөрү кагыйдәләрен исеңә төшер, әйтеп чык.
Берничәсен рәсем-схема рәвешендә ясап куй.



Әгәр дустым, сизгер булсаң,        Гомерем озын, үзем – нык,

Табышмаклар яратсаң,
Тагын җавап табып кара
Минем табышмакларга.

Ап-ак күлмәген кигән дә
Яшел шәлен ябынган.
Башкалардан өстен тора
Зифалыгы ягыннан.(каен)

Кызыл төймәсен аскан,
Каршыма килеп баскан. (миләш)

Ябалдашларым да киң.
Чикләвекләрем бар хәтта,
Йә, кайсыгыз миңа тиң?! (Имән)

Энәм озын чыршыдан
Төз үсәм баһадирдай. (Нарат)

Төсем наратныкы кебек,
Тик кыска шул энәләр.
Яңа елны каршыларга
Мине сорап киләләр. (Чыршы)

**Җавап бир.** Имән, каен, нарат, чыршы – бер сүз белән нәрсәләр?
Агачның күренми торган өлешен әйт.

**Бу кызыклы.** Каен тиз үсә, кышкы салкыннардан курыкмый яктылык ярата. Имән акрын үсә, корылыктан курыкмый, 300 ел яши. Агачлар кешеләргә һәм бөтен тере җаннарга сулау өчен кислород бүлеп чыгара.



Каен



Чыршы



Имән



Миләш

**Агач-йорт.**

Агач – ул йорт җәнлекләргә,
Кошларга, бөҗәкләргә:
Каргаларга, саесканга,
Үрмәкүч, күбәләккә.

Куышында яши тиен,
Ботагында кош, бөҗәк.
Хәйләкәр төлке түтәйгә
Агач шулай ук кирәк.

Тамырында оя корам
Мин, дускаем үзем дә.
Тырыш кырмыскалар тора
Шушында ук күршемдә.

**Бирем.** Агачларны буя. Буш урынга шигырьдә сөйләнгән агач –йортның рәсемен яса.

Урман буйлап йөргән чакта

Истә тот, дустым, шуны:
Урманда син  кунак кына,
Бозма һич тынычлыкны.

Табигать – ул тиңсез  хәзинә:
Матур чәчәк, яшел чирәм дә,
Кырмыска ул, шөпшә, яркanат.
Безгә кирәк аны сакларга.

Табигать – ул  тиңсез хәзинә:
Шаулы урман, елга-күлләр дә.
Яшел болын да ул, зәңгәр күк тә.
Сакла аны, аңа син тимә!



**Бирем.** 1.Рәсемне кара. Кеше куллана торган урман байлыкларын тап, кеше сурәте белән тоташтыр. Аңлат, кеше аларны ничек кулана ?

2. Рәсемнәр арасыннан нәрсәләрне җыярга кирәкми? Ни өчен?

Аларны  кызыл карандаш белән әйләндереп ал.

Сак бул, дустым, йөргәндә

Яшел хәтфә үләндә,
Аяк астыңа кара һәм
Күз сал син үләннәргә.
Бар алар арасында
Саклауга мохтаҗлары,
Дару кебек булганы,
Зәңгәре, сарылары…

1) Күп чәчәкләр белән бергә
Бер үк җирдә үсәләр.
Шифасы күп булган өчен,
Чәен ясап эчәләр. (мәтрүшкә)

2) Сары төсле бал кебек,
Ак чуклары – кар кебек.
Әллә ничә авыруга
Файдасы бар, эч белеп. (ромашка)

3) Нечкә бил сабакта
Юл буенда шар үскән.
Кай арада җил искән,
Ак шар очкан да киткән.(тузганак)

4) Охшасам да кыңгырауга,
Шалтырамыйм, чыңламыйм.
Эт эчәгесе шикелле,
Үләннәргә чорналмыйм. (кыңгырау чәчәк)


Мәтрүшкә


Тузганак


Ромашка


Кыңгырау чәчәк

**Бирем.** Табышмакларга җавап бир, рәсемнәрне буя.

**Бу кызыклы. Исеңдә тот! Мәтрүшкә** - дару үләне, шәмәхә чәчкә ата, салкын тигәннән кулланыла (ютәлне дәвалый). Чәчәге дә, яфрагы да бик файдалы. Саклауга мохтаҗ.
**Тузганак** яфрагының согы кан составын яхшырта, тешләрне ныгыта. Тузганакның тамыры да бик файдалы. Йокысызлыктан интеккәндә, аппетит булмаганда, ашказаны авырткандa кулланыла.
**Ромашка** авыртуны баса, ютәлдән бик файдалы, тамак авыртканда, тамакны да чайкасаң, бик файдасы тия. Аның чәчкәләре кулланыла.
**Кыңгырау чәчәк** – Кызыл китапка кертелгән.

**Ә хәзер сүзем үсемлек, хайван булмаган урман байлыгы турында барыр.**

Гәүдәсе бар – җаны юк,
Үзе эшләпә кигән – башы юк. (Гөмбә)



**Бу кызыклы! Агулы гөмбәләр.*****Чебен гөмбәсе.*** Кызыл эшләпәсендә ак таплар бар. Кеше өчен бу куркыныч гөмбә, аны ашарга ярамый. Әгәр кеше аны ашаса, ул исерек кебек әйләнгәләп йөри башлый. Ул хайваннарга кайбер чирләрдән арынырга ярдәм итә. Мәсьәлән, аны пошилар ашый.

***Поганка*** **гөмбәсе** - иң агулы гөмбәләрдән санала. Кеше аны ашаса үлә. Ул аксыл төстә, аягы нечкә, озын. Астарак түгәрәк боҗра
кигертелгән кебек өлеше бар. Эшләпәсе яшькелт ак булып та торырга мөмкин. Иске гөмбәләрдән черек бәрәңге исе килеп тора. Аларны гөмбәчеләр шампиньоннар, яшел төстәге сыроежкалар белән бутарга мөмкин. Шулай аерырга кирәк: шампиньоннарның эшләпәсе алсу төстә, ә сыроежкаларның аякларында түгәрәк боҗралары юк.

**Ашарга яраклы гөмбәләр.** ***Каен һәм усак гөмбәләре*** бер төркемгә керә.
Каен гөмбәсенең эшләпәсе күк, ә усак гөмбәсенең кызгылт төстә. Аның аягы зәңгәрсу булып та тора. Киптергәндә алар кара төскә керә, шунлыктан аларны күбрәк кыздырып ашыйлар.

***Ак гөмбә*** - ул бик тәмле, итле гөмбә, аны киптереп тә, тозлап та була. Аннан хуш ис килеп тора. Бүтән гөмбәләр киптергәндә каралалар, ә бу гөмбә төсен үзгәртми. Шуңа күрә аның исемен ак гөмбә дип атаганнар. Ә чынлыкта аның эшләпәсе караңгы кызгылт, аягы аксыл сары. ***Әтәч гөмбәсе*** - төлке төсендәге гөмбә. Шуңа күрә аны **русча « лисичка»** дип йөртәләр. Аның эшләпәсе дә, аягы да бер төстә. Бу гөмбә бервакытта да бозылган булмый. Искеләре корый яки череп юкка чыга. Ул бик тәмле гөмбәләрдән санала.

**Кагыйдәләр һәм киңәшләр.** Гөмбәне бик сак кына җыярга кирәк.

Аны пычак белән генә кисеп алалар да, кәрзингә салалар. Урманда мин аяк белән тапталган гөмбәләрне дә очратканым бар. Алай эшләргә һич кенә дә ярамый: үссеннәр, алар бит табигать байлыгы.

Яшьтән үк табигатьне сакларга өйрән. Гөмбәләрне таптамыйча гына йөр. Таныш булмаган гөмбәләрне өзмә. Урманда һәрнәрсәгә игътибарлы бул: агачларны сындырма, җәнлекләр тормышын күзәт, яшь агачлар утырт.

**Бирем.** Гөмбәләр турында табышмакларга җавап бир, рәсемнәрне буя.

**Табышмаклар.**

1) Күзгә ташланып торам, эшләпәм төрле төстә.
Мине күрү белән барсын бергә җыялар, чи килеш ашамыйлар. (Ал гөмбә)
2) Бөтен жир шарын гиздем, кызгылт эшләпә кидем. (Усак гөмбәсе.)
3) Кызыл эшләпә кигән, аңа ак тимгел тигән.
Бик матур гөмбә булса да, аңа мин тимәс идем. (Чебен гөмбәсе)
4) Төлке төсендәге гөмбә. (Әтәч гөмбәсе - лисичка)



**Ал гөмбә. (Сыроежки)**



**Усак гөмбәсе.**



**Әтәч гөмбәсе. (Лисичка)**



**Чебен гөмбәсе.**

## Җәнлекләр дөньясында.

Безнең урманнарда яши тагын
Күп төрле җәнлек-җанвар:
Тиен, куян, керпе, төлке,
Аю, бүреләр дә бар.

Араларында бар аның
Кызгылт, көрән, сорысы,
Үлән ашый торганы да,
Бар шулай ук ерткычы.

Табигатьтә барсы кирәк,
Берсе дә артык түгел.
Урманда йөргән чагында
Берүк син бик сак йөре.













**Беләсеңме?** Бүреләр – урман санитарлары. Алар хәлсез һәм чирле җәнлекләрне аулыйлар. Шуның белән чир таралуга юл куймыйлар. Көрән аю Кызыл китапка кертелгән.

**Сорау.** Бирелгән җәнлекләрнең кайсы ерткыч, ә кайсы – үлән ашаучы? **Бирем.** Ерткыч җанварларны кызыл төс белән, үлән ашаучыларны яшел төс белән әйләндереп ал, барлык җәнлекләрне дә төсле карандашлар белән буя.

Җимеш, үлән, яфраклар –
Ул яшәү чыганагы,
Кешенең дә, хайванның да
Бик кирәкле ризыгы.

Яшел кафе рәхим итеп
Ача сезгә ишеген,
Бал кортлары, күбәләкләр,
Кошчыклар, җитез тиен!

Кер, түрдән уз, аю абзый,
Син дә, куян, курыкма.
Керә ала хәтта поши
Безнең яшел кафега.

## Яшел кафе




**Бирем.** **1.**Рәсемне кара. Кафега кемнәр килгән? Исеңә төшер, төрле ел фасылында алар нәрсәләр белән туклана? Җавап бир.

**2.** Меню белән таныш, бөтен кунакларны яраткан ризыклары белән сыйла (тәлинкәләрдә яса), төсле карандашлар белән буя.

**3.**Аңлат әле, нигә бүре өстәл янына килми?

**4.**Төсле пластилиннан яки кәгазьдән төрле сый-нигъмәт яса һәм уенчыкларың белән «Яшел кафе»лы уйна.

Яшеллекне яклаучы,
Корткычлардан саклаучы
Канатлы дуслар турында
Бер сөйләшеп алыйкчы.

Әйдә, дустым, тагын бер
Табышмакка җавап бир.

Җылы яктан кайтуына
Өйләр ясап куябыз.
Хәтта кереп тә карамый,
Ошамаса оябыз. (сыерчык)

Оя кормый, ояда утырмый.
Йомырка басмый,
Баласын да бакмый. (күке)

Кара-кара түбәтәй кигән
Ап-актыр яңаклары.
Яшькелт-сары түшләре
Карасу канатлары. (песнәк)

Агач башы тукылдык,
Тукый-тукый тук булдык.
(тукран)



**Беләсеңме?**

**Күке** - урман кошы. Аны башка исем белән “кәккүк” дип тә йөртәләр. Ул агач яфракларын ашаучы йонлач кортларны ашап, урманны корудан саклый. Күке сәгатенә 100дән артык шундый корт ашый икән. Аның белән бер кош та ярыша алмый. Димәк, күке иң күп корт ашаучы кош.

**Песнәк** кайры ярыкларында кышлаган бөҗәкләр белән туклана. Бер пар песнәк кыш буена 40 төп җимеш агачын корткычлардан чистарта, миллионнарча бөҗәкләрне юк итә. Җәй көне песнәкләр балаларына ризык әзерләү белән мәшгуль була.

**Тукран** - урман докторы. Ул үзенең үткен томшыгы белән агач кәүсәләрен тикшерә, ябыштыручы озын теле белән кайры астыннан кортларны чүпли.

**Исеңдә тот!** Кошлар – яшеллек сакчылары. Дустым, берүк кошларны җәберләмә, ояларын туздырма, кош йомыркаларын ватма, кош балаларын кулыңа алма.





**тукран** **күке**



**песнәкләр**



**Бирем.** Кош рәсемнәрен төсле карандашлар белән буя.
Кошларга карата минем сүзләрне чагылдырган рәсем-схемалар яса.

## **Бөҗәкләр турында.**



Җәйнең матур көнендә күзәт әле, иренмә -
Көне буе эш кайный кырмыскалар илендә.
Ничек төзи белгәннәр: өйләре катлы-катлы.
Озын, урау юллардан чабалар бер-бер артлы.
Яңгыр килсә - посалар, өйләре – җылы, җайлы.
Бергәләшеп яшәгәндә башта юк һич тә кайгы.
Нәни генә кырмыска, ямьнәр өсти тормышка.
Җәй эшләсә, ял итәр – ерак калмады кышка.

**Сорауга җавап бир:** кырмыскалар яши торган өй ничек атала?

**Табышмакларга җавап тап.**

Аллы-гөлле очкалак,
Оча гөлләр кочкалап.
Чуар, йомшак күлмәге,
Тотсаң, уңа бизәге.
Тоттырмый, китә очып,
Йә кала җиргә качып. (күбәләк)

Тызлый да бызлый,
Үпкән җире сызлый.
Җәй буе бал җыя,
Кыш буе хәл җыя. (бал корты)

Үзе кечкенә булса да,
Үзеннән зур күтәрә. (кырмыска)

Чи-чик итә - читкә сикерә. (чикерткә)







**Бирем.** Рәсемнәрне буя. Бөҗәкләргә карата үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшер, ясап куй.



Юлыбызны дәвам итеп килдек без су буена.
Саф чишмәдәй чиста суда ак болытлар коена.



Су – ул йорт бик күпләргә:
Кошка, үсемлекләргә,
Балыкка, җәнлекләргә,
Хәтта кайбер бөҗәккә.

Суда нәрсә яши, үсә,
Нинди тере җан йөзә?
Син аларны беләсеңме?
Миңа әйтеп бирәсеңме?

1) Су буенда туебыз,
Чебен-черки сыебыз. (бака)

2)Тәне тулы тәңкәсе,
Елга – аның әнкәсе. (балык)

3) Борыны озын, боты озын,
Камышлыкта көнозын.
Сазлык җирләрдә йөри,
«Тату торыйк»,- дип сөйли. (торна)

4) Соскы борын – бакылдык
Күп сөйләшә - такылдык. (үрдәк)

5) Аягы – суда, башы - көндә,
Ак яки алсу төстә. (төнбоек)



**Бирем.** Рәсемне кара, суда һәм су буенда яшәүчеләрне ата.
Бакага нинди куркыныч яный? Ук белән күрсәт.
Аңлат, челәнгә озын аяк һәм томшык нигә кирәк? Рәсемне буя.

Утырганың бармы яр буенда, аның матурлыгын күзәтеп?! Кошлар җырын, суның шавын тыңлап, алам бары җанга мин сихәт.



Кама елгасында 40 төрле балык бар. Елгада алабуга, чуртан, корбан балыгы, чөгә, сазан балыклары бик күп. Менә аларның кайберләре:



**Корбан балык (лещ)** – Камада иң күпсанлы балыкларның берсе.



**Чуртан (щука)**

**Табышмакларга җавап бир.**

Тукмак кадәр башы бар,
Аршын ярым мыегы,
Ача калса авызын,
Йотар кебек сыерны. (җәен)

Шаян балык, чая балык,
Агым суда уйнаклый:
Чиртә, чиртә, чиртте!
Китте...
Ә кармакны һич капмый. (чабак)



**Җәен балыгын буя.**

Син тагын нинди балыклар беләсең, исеңә төшер, санап чык.
Түбәндәге турыпочмаклар эченә рәсемнәрен яса.

Беләсеңме, ерак түгел
Прось күленең барлыгын?
Күргәнең бармы син аның
Зурлыгын, матурлыгын?

Прось күленең яр буенда
Серләшәләр камышлар,
Төнбоеклар йөзә суда,
Гүя тере аккошлар.

Күлнең озынлыгы 8 км, киңлеге урыны белән 150 метрга җитә. Җәен Кама елгасы белән кушылу сәбәпле бик күп балык күлгә кереп кала.

**Исеңдә тот!** Сулыклар янында үзең генә йөрмә. Сулыкка чүпләр ташлама.

**Игътибар!** “Түбән Кама” милли паркында су кошы – аккошны очратырга мөмкин. Син аны кайда да булса күргәнең бармы? Аккошның кызыл китапка кертелгәнен беләсеңме?

**Бирем.** Түбәндәге аккош күлен төсле карандашлар белән буя.



## Табигатьтә мин эшләгән яхшы эшләр

Табигатьтә берни артык түгел:
Бөҗәк, кошлар, җәнлек, үсемлек.
Син аларны җәберләмә берүк!
Яхшы гамәл белән сөендер.
Нинди яхшы эшләр эшләдең син?
Тукта, уйлан, кара әйләнеп!
Бәлки әле хәзер берәрсенә
Кирәк менә синең ярдәмең.



Саклыйм.



Кошлар туйдырам.



Агач утыртам.

Мин – табигатьнең дусты.



Су сибәм.



Күзәтәм

**Бирем.** Табигатьтә яхшы эшләр рәсемнәрен кара. Уртага үзеңне яса, табигатьтә син эшләгән яхшы эшләрне белдергән рәсем-билгеләр белән тоташтыр. Буш тәрәзәләргә тагын табигатьтә яхшы эшләрне белдергән рәсем-билгеләрне яса.

Зурлар белән бергәләп агач утырт.

**Дустым, сиңа табигатьтәге тере жаннар турында кызыклы шигырьләр һәм ял минутлары тәкъдим итәм. Рәсемнәрне төсле карандашлар белән буя.**



***Ак күбәләк.***

Һавада уйный
Бер ак күбәләк.
Килче, күбәләк,
Уйныйк бергәләп.
Төште күбәләк,
Уйнаклап, очып,
Матур дөньяны
Куйнына кочып.
Кунды күбәләк
Бер кыз иңенә.
Шуңа сокланып
Торам мин менә.



***Бака.***

Камышлы күлдә,
Куак төбендә
Ята быгырдап
Зур башлы бака.
Черкиләр тотса,
Һәм аны йотса,
Ярсып сикерә,
Мактанчык бака.



***Тиен*** *.Әнәс Кари*

Урманда яши зур койрыклы тиен,
Агач башларында тора кышын, җәен.
Агачлардан агачларга сикереп үтә,
Чикләвекләр ашап шунда гомер итә.

***Камканы коткардым.*** *Шәүкәт Галиев*
Иделгә төшкән камка
Бер бата да бер калка -
Иделдә камка бата.
Йөзеп янына бардым,
Сөзеп кулыма алдым –
Камканы мин коткардым.
Ярга чыккач кипшенде,
Чистарынды, җилпенде,
Канатларын тикшерде.
Ашыгып китеп бара
Корткычлар бар бакчада!
Инде камка коткара...



***Гөмбәләр.*** *Мәрзия Фәйзуллина.*
Әйтерсең лә качыш уйный
Гөмбәләр безнең белән.
Мин ул шаян гөмбәләрне
Һич бутамыйм,
Бик оста эзли беләм.
Тик чебен гөмбәсе кебек
Агулысын өзмимен.
Нәкъ апабыз әйткәннәрен –
Яхшыларын эзлимен.
Ак, ал, кызыл гөмбәләрне
Табам да кисеп алам,
Җайлап, кәрзингә салам.



***Бал корты.****Мәрзия Фәйзуллина*
Апам безнең бакчабызда
матур бер гөл үстерде,
Ул гөл ап-ак чәчәк атты,
бик матур төскә керде.
Апам лагерьга киткәч,
мин шуны өзәргә булдым.
"Алам!" – диеп, гөлгә таба
тиз генә кулым суздым.
Шулчак бал корты безелдәп:
"Чәчәкне ө..з..ззз...мә!" – диде.
Сезгә тәмле бал җыярга кирәк ул
безззгә", – диде.



***Исәнләшү.*** *(бармак уены)*
Исәнме, җылы җилләр! (баш бармакны имән бармакка тидерү)
Исәнме, ямьле көннәр! (баш бармакны урта бармакка тидерү)
Исәнме, якты кояш! (баш бармакны атсыз бармакка тидерү)
Исәнме, яшел агач! (баш бармакны чәнчә бармакка тидерү)
Яшибез тату бергә, (бармакларны берничә тапкыр
Бездән күп сәлам сезгә. йодрыкка йомарлап җәю)

***Кошкай.*** *(ял минуты)*
Агачка кош утырган (кулларны җилкәгә кую)
Яңгыр яугач чыланган (бармаклар белән яңгыр яву хәрәкәтләре)
Җылы җилләр, исегез, (куш учка җылы сулыш өрү)
Кошчыкны киптерегез! (кулларны өстән аска таба селкү)

***Таң белән.*** *(ял минуты)*
Менә инде таң атты, (чүгәләгән җирдән торып басу)
Кояш җирне уятты. (кулларны як-якка җәю)
Бар кошлар уяндылар, (очу хәрәкәтләре ясау)
Канатларын кактылар (очу хәрәкәтләре ясау)
Чәчәкләр иркә генә (кулларны өскә күтәреп як-якка тибрәлү)
Тибрәлде таң җилендә.
Куянкай да уянды (кулларны алга бөкләп, кул чукларын
Һәм сикергәләп алды. аска каратып куеп куш аякта бер
урында сикерү)
Әйдәгез, дуслар, без дә (янындагы иптәшенә кулны бирү
Каршылыйк яңа көнне. кулларны өскә күтәрү)

***Бакалар.*** *(ял минуты)*
Сазлыктагы бакалар (сүзләр буенча хәрәкәтләр)
Бик иртә уяндылар.
Бата-калка, бата-калка
Битләрен дә юдылар,
Аннан соң зарядкага
Тезелешеп бастылар.
Уңга-сулга, уңга-сулга,
Алга-артка, алга-артка
Утырдылар, тордылар,
Сузылып-киерелделәр,



**Чәчәкләр.** *(ял минуты)*
Гөлчәчәкләр күренде (балалар басалар)
Һәм кояшка үрелде (кулларын югары күтәрәләр).
Аларга җылы кирәк,
Кояш астында рәхәт (сузылалар).
Менә кинәт җил исте (чайкалалар),
Чәчәкләрне селкетте.
Аллы-гөлле чәчәкләр
Уңга бөгелделәр (бөгеләләр),
Җиргә иелделәр (чүгәлиләр),
Сулга бөгелделәр (бөгеләләр),
Җиргә иелделәр (чүгәлиләр),
Бар инде, җил, моннан кит (башларын калкыталар),
Чәчәкләргә тими үт, (куллар белән алга таба этү хәрәкәтләре)
Алар зур булып үссен (сузылалар),
Безгә шатлык китерсен (утыралар).





**Кулланылган әдәбият исемлеге.**

**1.** Борһанова Р. А. Туган як табигате белән таныштыру: балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен кулланма. 1 кисәк. – Казан: ИПКРО РТ, 2002. - 172 б.

**2.** Закирова К. В. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-
әниләр өчен хрестоматия. — Казан: РИЦ, 2011. — 560 б. ISBN 978-5-4378-0030-0

**3.** Николаева С. Н. Юный эколог. Система работы с детьми в старшей группе детского сада. Для занятий с детьми 5-6 лет. – М.: Мозайка-Синтез, 2010. – 152 с.: цв. вкл.

**4.** Николаева С.Н. Воспитание экологической культуры в дошкольном детстве: методика работы с детьми подгот. группы дет. сада: пособие для воспитателя дошк. образоват. учреждения – 2-е изд. – М. : Просвещение, 2005. 144с. : ил. – (Дошкольный мир). – ISBN 5-09-014541-5

**5.** Николаева С.Н. Познаём природу – готовимся к школе: эколог. тетр. для детей шестилетнего возраста / Николаева С.Н., Н.А. Волкова. – М. : Просвещение, 2009. – 55с. : ил. – (Скоро в школу). - ISBN 5-09-018544-8.

**6.** Экология иленә сәяхәт. Экологик тәрбия буенча методоик әсбап.

**Түбән Кама милли паркында саклауга мохтаҗ кошлар**



**Ысылдавык аккош**

Оя ясаучы аз санлы күчмә төр, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының су яны һәм су асты үләннәре күпләп үскән култыкларда, Сукыр Кадыш һәм Кайбыч балык үрчетү хуҗалыгы буаларында апрельдән октябрьгә кадәр яши.



**Елга́ каракошы́ (*аккойрык бөркет*)**

Татарстанда Идел һәм Кама елгалары үзәннәрендә очрый. Оя коручы күчмә төр.

**Бу кошлар Татарстанның Кызыл китабына кертелгән**

## Растения произрастающие на территории Национального Парка "Нижняя Кама"



**Касатик сибирский**
Произрастает
в Елабужских лугах.



**Линнея северная -**
- Большой бор



**Горечавка легочная -**
Елабужские и Танаевские
пойменные луга.

## Птицы обитающие на территории Национального Парка "Нижняя Кама"



**Неясыть длиннохвостая -**
Боровецкий лес, Большой и
Малый боры, гнездящийся вид.



**Щурка золотистая -**
встречается в Елабужских лугах,
гнездящийся вид. Включён в
Красную книгу РТ.



# *Весёлое путешествие по родному краю*



Копирование, переиздание запрещены.
Все авторские права защищены.

Компьютерная верстка, издание.
Отпечатано в типографии
Нижнекамский региональный учебно-методический центр
г.Нижнекамск, ул. Бызова, 9
e-mail: umc-biz@mail.ru
Лицензия на издательскую деятельность № 06157.